# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Буа районы һәм Буа шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Буа районы һәм Буа шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 129-ТРЗ

"Татарстан Республикасы Буа районы һәм
Буа шәһәре буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы
Законына кушымта

**Татарстан Республикасы Буа районы һәм Буа шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнчыгыш чигендә Казан урамының Буа әйләнгеч юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Казан урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Жорес урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Жорес урамы күчәре буйлап төньякка таба Жорес урамының Космовский урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Космовский урамы күчәре буйлап көньякка таба Б.Хмельницкий урамына кадәр, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Б.Хмельницкий урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Ефремов урамына кадәр, аннары Ефремов урамын төньяк-көнбатыш юнәлешендә Б.Хмельницкий тыкрыгына кадәр кисеп үтә, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап көнбатышка таба Казан трактына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Казан трактының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба Гагарин урамы һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр, аннары, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап төньяк-көнбатышка таба шәһәрнең төньяк чигендә "Буа шәһәре", Кайбыч һәм Ырынгы авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең көнчыгыш чигендә Казан урамының Буа әйләнгеч юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Буа муниципаль районының Адав-Толымбай, Аксу, Бик-Үти, Зур Фролово, Югары Лашчы, Исәк, Кайбыч, Кыят, Түбән Наратбаш, Яңа Чәчкап, Норлат, Ырынгы, Күл Черкене, Килдураз һәм Яшевка авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Буа шәһәре", Ырынгы һәм Кайбыч

авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре чикләре тоташкан урында шәһәрнең төньяк-көнбатыш чигенең Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җирдә урнашкан тоташу ноктасыннан алып, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап көньяк-көнчыгышка таба Гагарин урамы һәм Казан тракты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны һәм «Көнбатыш» микрорайонын кертеп, Казан тракты күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгыш юнәлешендә Б.Хмельницкий тыкрыгына кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап көнчыгышка таба Ефремов урамына кадәр, аннары Ефремов урамын көньяк-көнчыгышка таба кисеп үтә һәм Б.Хмельницкий урамына килеп чыга, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, әлеге урамның күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Космовский урамына кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Космовский урамы күчәре буйлап төньякка таба Жорес урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Жорес урамы күчәре буйлап көньяк юнәлешендә Казан урамына кадәр уза, аннары, зиратны һәм уң якта урнашкан йортларны кертеп, Казан урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба шәһәрнең көнчыгыш чигендә Буа әйләнгеч юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба "Буа шәһәре", Ырынгы һәм Кайбыч авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Буа муниципаль районының Әлши, Алших, Боерган, Күшке, Шәмәк, Татар Буасы, Карлы, Мөкерле, Яңа Тинчәле, Кырык Садак, Иске Суыксу, Иске Тинчәле, Тимбай, Чуаш Киштәге һәм Янтуган авыл җирлекләре.